ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2025 ел Баулы шәһәре №188

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 228 номерлы карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (2015 елның 27 октябрендәге 294 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге 310 номерлы, 2016 елның 10 маендагы 133 номерлы, 2017 елның 9 мартындагы 88 номерлы, 2019 елның 22 августындагы 243 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге 6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 февралендә 100 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 228 номерлы карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенә (2015 елның 27 октябрендәге 294 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге 310 номерлы, 2016 елның 10 маендагы 133 номерлы, 2017 елның 9 мартындагы 88 номерлы, 2019 елның 22 августындагы 243 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге 6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.3.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3 Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр буенча исәпләнә.».

Түләүне билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме түләү билгеләү турында гариза бирү аена кадәрге айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

2 «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» бүлегендә:

2.1. пунктның б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) гаиләнең һәр әгъзасы керемнәре турында документлар өстәмә компенсация бирү турында гариза биргән айга кадәрге соңгы 12 календарь айда;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров